РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Ленин ур, 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел. факс (885592) 7-15-50, 7-00-37, E-mail: aznakay@tatar.ru; adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2019 ел № 37

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган оешмалар һәм территорияләр объектлары янындагы чикләрне раслау турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» 1995 елның 22 декабрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнар күпләп тупланган урыннарны һәм югары куркыныч чыганакларын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү турында, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын урыннарның чикләрен билгеләү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең 2013 елның 28 августындагы 100-30 нче номерлы «Азнакай муниципаль районы территориясендә этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» карары нигезендә карар бирәм:

1. Расларга:

- яңа редакциядә, 1-42 нче кушымталар нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын урнашкан чикләр схемаларын.

2. Әлеге карарны утыз көн эчендә этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин

итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенә җибәрергә.

3. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмалар һәм территорияләр объектлары янындагы чикләрне билгеләү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 20 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.И.Солтанов